СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Решение**

№ 1-9 «10» июнь 2021 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карарына Мамадыш районы прокуратурасының 2021 елның 26 маендагы № 02-08-02-2021 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (03.03.2016 № 1-6 ( от 18.11.2016 №2-14, 15.05.2017 №1-20, 28.07.2017 №3-21, 14.11.2017 №2-25, 05.06.2018 №2-32, 13.08.2018 №2-34, 20.11.2018 №3-37, 14.12.2018 №2-38, 21.03.2019 №1-40, 18.09.2019 №3-45, 19.02.2020 № 1-50) 17.11.2020 № 3-2) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 статьяның 5.15 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында белешмәләр шәхси эшкә һәм муниципаль хезмәткәрнең хезмәт кенәгәсенә (булганда) кертелә»;

1.2. 7 статьяның 7.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазифа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар»;

1.3. 25 статьяның 25.11 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы И.З.Исмагиловны билгеләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.З.Исмагилов/